**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**«09» август 2023 ел** **№ 186**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында**

Территорияне тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу, җирдән тәртипле һәм нәтиҗәле файдалануны һәм «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта камыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзелешне тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, муниципаль берәмлек уставы нигезендә, Урта Камышлы авыл җирлегенең 2023 елның 10 июлендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш буенча кушымтада бирелгән Кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы рәисе Д.А. Ишкинеев